**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе Таҗи Гыйззәт исемендәге 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Тема: “Юлларда сак булыгыз!” темасын кабатлау

**8 нче сыйныфның рус төркемендә татар теле.**

**Сингапур укыту методын кулланып уздырылган ачык дәрес эшкәртмәсе**

**Укытучы: Зиннәтова Л. И.**

**2014 ел**

**Дәреснең максатлары:**

**1. Белем бирү максаты** – Укучыларның “Юлларда сак булыгыз” темасы буенча алдагы дәресләрдә өйрәнгән белемнәрен: темага бәйле лексиканы искә төшерү, **-ганда/-гәндә ,-канда/кәндә** конструкциясен кабатлау, сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләре булдыру;

**2. Фикер сәләтен үстерү максаты -** Укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.

**3. Тәрбияви максат -** аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру; юл йөрү кагыйдәләрәре турында белемнәрне ныгыту, урамда йөргәндә игътибарлы булырга, юл кагыйдәләренә буйсынырга өйрәтү

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, экран, тема буенча мультимедиа презентация, “Татарча да яхшы бел” 8 сыйныфы өчен аудиокушымтасы,кагыйдәләр, карточкалар

**Таратма материал:** битләр,карточкалар, терәк лексика

**Дәреслек:** Ф.С. Фәизова, В.АВ. Яковлева. , “Татарча да яхшы бел” : Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). – Казан: Мәгариф, 2008.

**ДӘРЕС ТИБЫ :** белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру, ягъни кабатлау-йомгаклау дәрес.

**МЕТОД ҺӘМ АЛЫМНАР:** Практикум дәрес, биремнәр үтәү.

**КУЛЛАНЫЛГАН СТРУКТУРАЛАР :**

**- МЭНЭДЖ МЭН,**

**- КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД,**

**- МИКС-ФРИЗ-ГРУП,**

**- ДЖОТ ТОТС**

**- ТИК - ТЭК – ТОУ,**

**- КОНТИНИУС РАУНД РОБИН.**

**Дәрес барышы.**

1. **Оештыру өлеше: Хәерле көн! 1 нче слаайд.**

1) Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру. Хәерле көн теләү. Кунаклар белән исәнләшү.

Укучы: Исәнмесез, укытучы апа, хәерле көн сезгә!

2)Укучыларның дәрескә әзерлекләрен тикшерү. ХАЙ ФАЙВ структурасы ярдәмендә (Дәрескә кирәкле әсбабларны барлау).

3)Дежур укучының җавабы. -Бүген сыйныфта кем дежур?

Дежур укучыга укучылар сораулар бирәләр.(Бүген ничәнче число?Атнаның нинди көне?Урамда көн нинди? Бүген дәрестә кемнәр юк?)

Укытучы: Бик яхшы.

3) Дәрес максатын хәбәр итү. Экранга карыйбыз. Бу дәресебезнең эпиграфы. Бер укучы укый.

“ Юлда йөр**гәндә**, бул сак, юл кагыйдәсен нык бел!” **(2 нче слайд**)Тәрҗемә итәбез. Аңлатабыз.

- Бүгенге дәрестә без сезнең белән төрле структуралар кулланып “Юлларда сак булыгыз” темасы буенча лексиканы искә төшербез, **-ганда/-гәндә ,-канда/кәндә** конструкциясен кабатларбыз.

**2.Фонетик күнегү.** **<u>3 нче слайд</u>.[ ә ],[ ө ], [ ү ], [ җ ] , [ къ ]** авазлы сүзләрне дөрес әйтү уенын оештыру. Хәзер экранга карыйбыз. Һәрбер авазны дөрес итеп минем артымнан кабатлагыз.
(экранда слайд №1)
Беренче төркем - [ ә ] авазы , икенче төркем - [ ө ], өченче төркем - [ ү ], 4 нче төркем - [ җ ], 5 нче төркем - [ къ ] авазы булган сүзләрне генә әйтергә тиеш. Сүзләр дәресебезнең темасына туры килсә, тагын да яхшырак булыр. Төркемдә һәр укучы сүз уйлый, беренче сүзне 1 нче номерлы укучылар әйтәләр, шулай тәртип буенча барабыз, башлыйбыз 1 нче өстәлдән. Моның өчен 30 сек бирелә. Вакыт бетте.

**Һәрбер авазны дөрес итеп минем артымнан кабатлагыз, мисалларны әйтегез: <u>4 нче слайд</u>**

| |
|---|
| **[ ә ] хәрәкәт**, һәлакәт, тәгәрмәч, көтмәгәндә, шәһәр, белешмә, **билгеләр, кагыйдә** **[ ө ]** йөрү, **мөһим**, йөргәндә, бөтен, көн **[ ү ] тәүлек** , үтәгәндә, **күпер,** кисәтү, үскәндә **[ җ ]** божра, **фаҗига**, **җәяүле**, җир асты, җир өсте, җиңел, җитез **[ у ]** урам, юл, уздырганда, ут, **сулга, уңга**,тукталыш, туры, уңайлы, туктаганда |

**Дәфтәрләрдә эш. .** Молодцы, дәфтәрләрегезне аласыз,бүгенге числоны язасыз,атна көнен язып куябыз ,сыйныф эше. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне тәрҗемәсе белән күчереп язасыз. (Терәк лексиканы кулланырга була).
**5 нче слайд**

**<u>6нче слайд .</u>** *Казан метросы*

**3. Өй эшен тикшерү**.- Өй эшенә сезгә “ Казан метросы” тексты буенча 3 сорау язып килергә иде.Дәреслекләрнең 65 нче битен ачабыз. 3 нче күнегүне тыңлыйбыз.
- Сез хәзер **КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД (опроси-опроси-обменяйся)**структурасы ярдәмендә бер – берегезнең белемнәрегезне тикшерерсез.
- Моның өчен сезгә карточкаларны алырга кирәк булачак. ( Карточкалар өстәлдә)
Битнең астын 4\1 өлешен бөкләргә кирәк була.(Күрсәтелә).
-Битнең күренә торган өлешенә сез иң яхшы дип саналган соравыгызны язасыз,ә күренми торган өлешенә соравыгызга җавабы языла.
- Моны эшләү өчен сезгә 2 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды (Таймер куела)

**7 нче слайд. Казан метросы.**
- Хәзер сез торасыз, урындыкларыгызны этеп куясыз. Кулыгызны күтәрәсез, якында булган иптәшегез янына барасыз һәм соравыгызны бирәсез, иптәшегез сорауга җавап бирергә тиеш. Иптәшегез сорауга җавап бирә алмаса сез аңа булышасыз. Дөрес җавап ишеткәннән соң иптәшегезне мактыйсыз һәм аның соравын тыңлап җавап бирәсез. Бергә кабатлыйбыз “Молодец, рәхмәт миңа синең белән эшләргә бик рәхәт булды”
. Моннан соң сез карточкаларыгыз белән алмашырга тиеш буласыз. Элеге эшне сез 3 тапкыр кабатларга тиеш буласыз.
- Барыбызда басттык,урындыкларны төзәттек.Парлар табабыз.Беренче булып үз соравын чәче озынрак булган укучы әйтә.Эш беткәч сез үз урыннарыгызга утырырга тиеш буласыз.
- Эшли башладык .
- Вакыт бетте, үз урыннарыгызга үтәсез һәм утырасыз. Молодцы.

**4. <u>Белем һәм күнекмәләрне ныгыту. 8 нчы слайд</u>**

1)-**Укучылар,күптән түгел без сезнең белән түбәндәге конструкция белән танышкан идек. Искә төшерик. Экранга карыйбыз. Бер укучы кагыйдәне искә төшерә.** Для того ,чтобы сказать когда ,в то время в предложении к повелительному глаголу добавляем окончания -ганда/-гәндә ,-канда/кәндә

**!** + -Ганда/ -гәндә
-канда/кәндә → -когда../в то время когда...

Юл аша ЧЫККАНДА,мин светофорга карыйм.-Когда я перехожу через дорогу,я смотрю на светофор.

**2)Эш дәфтәрләрендә күнегүләр эшләү.**

Шушы конструкцияне кулланып эшлибез. <u>Эш дәфтәрләреннең 55 нче битен ачабыз, 3 нче күнегүне эшлибез</u>. Татарчага тәрҗемә итегез. Бергәләп эшлибез. Бер укучы укый, тәрҗемә итә. Язып куябыз. Тактада да эшлибез. Терәк лексиканы файдаланабыз. (Экранда чыгырыла)

**3)Ситуатив күнегүләр.** Шушы конструкцияне кулланып ситуатив күнегүләр үтәү *(Баларның белем дәрәҗәсенә карап)*

Посоветуй другу о том, что когда он переходит через дорогу…
- знал правила дорожного движения;
- смотрел сначала на левую сторону, а потом на правую сторону;
- был внимательным;
- был осторожным;
- переходил дорогу через «зебру»
- переходил дорогу на зелёный свет;

**<u>Ял минуты.</u>** “Курай денс” көенә йөриләр. Музыка туктый.Сорау бирелә. Сораудагы җавап санына карап берләшәлә ***МИКС – ФРИЗ – ГРУП (Mix-Freeze-Group) куллану***

- Ә хәзер укучылар бераз ял итеп алабыз. – Бастык ,урындыкларны рәтләдек.Укучылар, без хәзер барыбыз да бер әйләнә ясап басабыз. Музыка кушыла, сез шул музыкага бии-бии әйләнәсез. Музыка туктагач, сез бер урында басып каласыз. Шуннан соң мин сезгә сорау бирәм, сез шул сорауның җавабын миңа укучылар саны ярдәмендә күрсәтергә тиеш буласыз.

Светофорның ничә төсе бар? (3)
Чатта ничә юл кисешә? (4)
Җәяүле сүзендә ничә аваз бар? (7)
Әгерҗе шәһәрендә ничә вокзал бар? (1)
Юлларда сак булыгыз! җөмләсендә ничә сүз бар? (3)
Атнада ничә көн? (7)
Бөген сезнең ничә дәрес булды? (6)
- Рәхмәт ,урыннарга утырабыз.

-ХАЙ ФАЙВ.

.- Алдагы эшне без **ДЖОТ ТОТС** структурасы ярдәмендә үтиячәкбез. “Запишите мысли” ( уйларыгызны языгыз) дигәнне аңлата. Сезнең һәрберегездә өстәлдә 4 карточка. Сез “ Юлларда сак булыгыз” темасыны сүзләр язырга тиеш

буласыз.Стенадагы плакаттан карап бер укучы бу структурага карата язылган инструкцияне укый.1.Придумайте одно слово, связанное с темой “ Юлларда сак булыгыз” . 2. Проговорите это слово громко для членов вашей команды изапишите на доном листочке бумаги.
3. Положите на центр стола лицевой стороной вверх
4. Повторите шаги 1-3, пока вы не используете все листочки. Не соблюдая очередности, каждый участник должен заполнить 4 листочка, следовательно, в центре стола окажутся 16 листочков.
Вакыт башланды. (Таймер куела.)
Вакыт беткәннән соң бер укучы үзләренең өстәлендәге барлык сүзләрне укып чыга.
Дәфтәрләрдә эш. Молодцы, дәфтәрләрегезне аласыз. Хәзер сез дәфтәрегезгә җөмләләр төзеп язып куярга тиеш буласыз.
Хәзер эшне ТИК - ТЭК – ТОУ(крестики нолики) структурасы ярдәмендә дәвам итәбез.
1 укучы плакаттан бу структурага булган инструкцияне укый.
- Моның өчен сезнең өсләлләрегездәге 16 нчы карточкадан 9 ны гына калдырасыз.
- Икенче номерлы партнер әлеге битләрне өстәлнең уртасына ,тәртип буенча 3*3 рәвешендә урнаштыра.

- Сез хәзер сүзләрдән 3 җөмлә төзергә тиеш буласыз.Ләкин теләсә ничек түгел, яки горизонталь ,яки вертикаль,яки диагональ буенга.
- Башка сүзләр өстәргә ярый.
- Җөмләләр төзи башлаганчы сез сүзләрне нинди тәртиптә кулланасыз , язып куярга тиеш буласыз.Сезгә моның өчен 3 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды.(Таймер куела).
- Вакытыгыз бетте.Хәзер сез КОНТИНИУС РАУНД РОБИН (продолжительный раунд робин) структурасы ярдәменә командада бер-берегезгә чират буенча җөмләләрегезне укыйсыз. Беренче булып дүртенче номерлы партнер үзенең беренче җөмләсен укый һәм шулай чылбыр буенча эшне дәвам итәбез. Аннары икенче җөмләне укыйсыз һәм өченче җөмләне.
- Моның өчен сезгә 3 минут вакыт бирелә.вакыт китте (Таймер куела)
- . Минем ........ өстәлдәге ....... номерлы укучының җөмләсен ишетәсем килә. Нинди сүзләр кулландың? Җөмләне тактага языла.Җөмләләр дөрес төзелмәсә төзәтәсез (Берничә укучының җөмләләре укыла.) Укучылар дәфтәрләрдә эшлиләр.

- Минем ........ өстәлдәге ....... номерлы укучының җөмләсен ишетәсем килә. Нинди сүзләр кулландың?

5. **Тест эшләү**

**9 нчы слайд.**.Хәзер юл йөрү кагыйдәләре буенча тест сорауларына җавап бирәбез. Тестта 10 сорау. Экранга карыйбыз. Бер укучы сорауларны укый. Аңлатма бирәбез. Дәфтәрдә эшлибез
1. Юл аша чыкканда башта кайсы якка карарга кирәк?
а)уңга б)сулга в) туры
2. Дөрес тәрҗемәне күрсәтегез.
*Дорожное движение*.
а) юл хәрәкәте б) юл чаты в) юл кырые
3. Дөрес тәрҗемәне күрсәтегез.
Беспорядок на улице опасен для жизни людей.
а) Урамдагы тәртипсезлек кешеләргә куркыныч.

б) Урамдагы тәртипсезлек кеше гомере өчен куркыныч.
в) Урамдагы тәртипсезлек кеше өчен куркыныч.
4. Җөмләнең соравын күрсәтегез.
*Әйе, мин юлда йөрү кагыйдәләрен яхшы беләм.*
а)Син юлда йөрү кагыйдәләрен беләсеңме?
б) Син юлда йөрү кагыйдәләрен кайчан өйрәндең?
в) Син юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәнәсеңме?
5. Дөрес тәрҗемәне күрсәтегез.
Юл аша чыкканда, игътибарлы булыгыз.
а) Когда переходите через дорогу, будьте осторожны.
б) Когда едете на траспорте, уступите место пожилым людям.
в) Когда переходите через дорогу, будьте внимательны.
6. Кайсы вариант дөрес түгел?
<u>19.52</u>
а) унтугыз сәгать илле ике минут
б) сигез тулырга сигез минут
в) җиденче илле ике минут
**10 нчы слайд**
7. Бу билге нәрсәне аңлата?



а) Туктап тору тыела
б) Велосипедта йөрү тыела.
в) Җәяүлеләргә чыгу юлы
г) Җир астыннан үтү юлы.

8. Бу билге нәрсәне аңлата?



а) Җәяүлеләргә юл юк.
б) Велосипедта йөрү тыела.
в) Җәяүлеләргә чыгу юлы
г) Машина белән керү тыела.
9. Беренче урам светофоры нинди шәһәрдә барлыкка килгән?
а) Мәскәүдә
б) Парижда
в) Чикагода
г) Лондонда
10. Бу рәсемдә нинди вокзал?
А) Әгерҗе вокзалы

Б) Казан вокзалы
В) Мәскәү вокзалы

**Билгеләү. 11 нче слайд**

0-1 - “5”
2-3 - “4”
4-5 - “3”
6-10 - “2”

Биткә - бит партнерлар дәфтәрләрен алышалар, билге куялар.

**6. Рефлексия. Парковка**

Дәреснең темасы нинди? Нәрсә истә калды?Нәрсә ошады?
Напишите свои впечатления об уроке на стикерах и приклейте к парковке.
На экране**. 12 нче слайд** “ Уңышлар баскычы” ( “ Лесенка достижений”)

- Миңа кызык булды.
- Миңа авыр булды.
- Мин аңладым
- Дәрестә үз эшемнән канәгать (доволен)

Дәрестә барыгыз дә яхшы эшләдегез.

7.**Өй эше бирү.**

Көндәлекләрне ачыгыз. Дүшәмбегә өй эшен язып куегыз.

“ Юлларда сак булыгыз” темасына рәсем( постер, памятка, буклет) ясарга.
Киләсе дәрестә эшләрегез буенча әңгәмә корырбыз.

**10.Йомгаклау.**

Дәрес тәмам. Тырышлык булса, уңышлар да булыр!
Сау булыгыз, укучылар!